ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре. 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» май 2019 ел. № 209

2019 елда салым салынырга тиешле гражданнарның максималь керем күләме һәм мөлкәт хакын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 маддәсе, 2015 елның 16 мартыннан 13-ТРЗ санлы «Соңиаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче кешегә туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм әлеге законга кушымтада бәян ителгән гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче салым салынырга тиешле кешенең мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, “2019 елның II кварталына Россия Федерацияse субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метр уртача базар бәясе күрсәткечләре турында" Россия Төзелеш Министрлыгының №197/пр боерыгына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарны найм килешүләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаж дип тану турында Карар кабул итү өчен, 2019 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче салым салынырга тиешле кешегә туры килә торган керемнең һәм мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 523 610,0 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен –1 939 140,0 сум;

1.1.3. өч кешелек гаиләләр өчен - 2 493 180 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 3 324 240,0 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 4 155 300,0 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 4 986 360,0 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420,0 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 44 034,0 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 28 022,0 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 24 019,0 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә куйганда Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш,архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарны agryz.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И.Шамсутдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**

Кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елда салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү хакында МЕТОДИКА**

1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече
СЖ= НП*РС* РЦ, кайда:
СЖ - соңиаль наем шартнамәсе буенча базар хакының исәп-хисап күрсәткече яисә торак урыны сатып алу бәясенең иң чик күрсәткече;
НП — муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;
РС — гаилә әгъзаларының саны;
РЦ - РФ Төзелеш Министрлыгының 2010 елның 1 апреленнән 197/пр номерлы боерыгы нигезендә бер квадрат метр мәйданның уртача исәпләнгән базар бәясе (2019 елның икенче кварталына - 46 170 сум)
а) ялгыз яшәүче граждан өчен: СЖ=46 170*33=1 523 610
б) ике кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170*42=1 939 140
в) өч кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170* 18*3=2 493 180
г) дүрт кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170* 18*4=3 324 240
д) биш кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170* 18*5=4 155 300
ж) алты кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170*18*6=4 986 360
з) җиде кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170*18*7=5 817 420

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме - ПД=0,7*СЖ*ПС/ (1-[(1+ПС) - КП]}/ (0,25*РС), кайда:

СЖ — наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакын исәпләү күрсәткече;

ПС - кредит буенча айлык проңент ставкасы (8,55/12);

КП — кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС — гаилә әгъзаларының саны;

0,7 — кредит суммасының фатир хакына карата нисбәте;

0,25 — кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма керменә карата нисбәте;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
ПД=(0,7*1 523 610*1,15) / (1-[(1+1,15) - 180]}/ (0,25*1)= 27 430,94
б) ике кешедән торган гаиләгә:
ПД=(0,7*1 939 140*1,15) / (1-[(1+1,15) - 180]}/ (0,25*2)= 17 456,05
в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:
ПД=(0,7* 2 493 180*1,15)/ (1-[(1+1,15) - 180]}/ (0,25*3)= 16 762,72